ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» апрель, 2019 ел** **№ 270**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын раслау турында» 2010 елның 04 февралендәге 84 нче номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү турында**

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын раслау турында» 2010 елның 04 февралендәге 84 нче номерлы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4. пукнтын түбәндәге редакцидә бәян итәргә: «Административ комиссия составына даими штат нигезендә административ комиссиянең җаваплы сәркатибе керә. Административ комиссиянең башка әгзалары, әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган очраклардан тыш, административ комиссиядә җәмәгать башлангычларында эшли. Җаваплы сәркатип булмаган очракларда аның вазыйфаларын административ комиссия рәисе карары белән вакытлыча комиссиянең башка әгзаларына йөкләнә».

«Административ комиссия утырышына чакыру һәм үткәрү тәртибе» 3 бүлегенә 3.8. пунктын өстәргә: «Административ комиссия утырышы вакытында кино-, видео- һәм фотога төшерү административ комиссия рәисе рөхсәте белән башкарыла».

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин